**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**«15» сентябрь, 2021 ел** **№ 105**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2014 елның 31 мартындагы 352 номерлы «Биектау муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренә классы чиннар бирү һәм саклау тәртибе турындагы, Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең квалификация имтиханын тапшыру һәм аларның белемнәрен, күнекмәләрен һәм осталыкларын (һөнәри дәрәҗәсен) бәяләү тәртибе хакындагы нигезләмәләрне раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарында гражданнарның муниципаль хезмәткә урнашуга тигез мөмкинлеге өлешендә муниципаль хезмәтнең төп принципларын гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2014 елның 31 мартындагы 352 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренә классы чиннар бирү һәм саклау тәртибе турындагы, Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең квалификация имтиханын тапшыру һәм аларның белемнәрен, күнекмәләрен һәм осталыкларын (һөнәри дәрәҗәсен) бәяләү тәртибе хакындагы нигезләмәләргә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең квалификация имтиханын бирү тәртибе һәм аларның белемнәрен, күнекмәләрен һәм осталыкларын (һөнәри дәрәҗәсен) бәяләү турында нигезләмәгә 2 нче кушымтада 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри сыйфатларын бәяләү ысулларын кулланып, Россия Федерациясе Конституциясен һәм Татарстан Республикасы Конституциясен, муниципаль хезмәт турындагы, коррупциягә каршы көрәш турындагы законнар нигезләрен белүне үз эченә алган, Татарстан Республикасы кадрларын бәяләүнең махсус эшләнгән системасында уздырыла торган индивидуаль әңгәмәне һәм тестлаштыруны да кертеп (60 сорау), имтихан процедуралары нигезендә квалификация имтиханын үткәргәндә, комиссия муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләре таләпләре, муниципаль хезмәткәрләр башкара торган эшнең

катлаулылыгы һәм җаваплылыгы нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең белемнәрен, күнекмәләрен (һөнәри дәрәҗәсен) бәяли;

2) 14 пунктта «нәтиҗәләре буенча» сүзләре алдыннан «һәм тестлаштыру» сүзләре белән тулыландырырга;

3) 15 пунктта «нәтиҗәсе» сүзе алдыннан «һәм тестлаштыру» сүзләре белән тулыландырырга;

4) 17 пунктта «нәтиҗәләре нигезендә» сүзләре алдыннан «һәм тестлаштыру» сүзләре белән тулыландырырга;

5) 20 пунктта «тапшырмаган» сүзе алдыннан «һәм тестлаштыру» сүзләре белән тулыландырырга;

6) Татарстан Республикасы Биектау районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан квалификация имтиханын бирү тәртибе һәм аларның белемнәрен, күнекмәләрен (һөнәри дәрәҗәсен) бәяләү турындагы нигезләмәгә 4 нче кушымтада муниципаль хезмәткәрнең Имтихан кәгазендә 9 пунктта «муниципаль хезмәткәргә сораулар һәм аларга кыска җаваплар» дигәнне төшереп калдырырга, «тестлаштыру нәтиҗәләре (балларда)» сүзләрен өстәргә;

7) 12 пунктта «нәтиҗәләре буенча» сүзләре алдыннан «һәм тестлаштыру» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г. Кәлимуллин